РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
БУИНСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЧЕРКИ-ГРИШИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БУА
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
КҮЛ-ЧЕРКЕН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

---

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

22.05.2025 № 5

«Күпфатирлы йортта урыннарны үзгәртеп коруны һәм (яисә) яңадан планлаштыруны килештерү һәм кабул итү комиссиясе тарафыннан күпфатирлы йортта урыннарны яңадан үзгәртеп кору һәм (яисә) яңадан планлаштыру турында актны рәсмиләштерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» Буа муниципаль районы Күл Черкене авыл җирлеге Башкарма комитетының 2021 елның 9 августындагы 22 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 27.07.2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, ТР Буа муниципаль районы Күл Черкене авыл җирлеге Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. «Күпфатирлы йортта урыннарны үзгәртеп коруны һәм (яисә) яңадан планлаштыруны килештерү һәм кабул итү комиссиясе тарафыннан күпфатирлы йортта урыннарны яңадан үзгәртеп кору һәм (яисә) яңадан планлаштыру турында актны рәсмиләштерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» Буа муниципаль районы Күл Черкене авыл җирлеге Башкарма комитетының 2021 елның 9 августындагы 22 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1.5 пунктның 6 абзацын үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә;

«Күпфатирлы йортта урынны үзгәртеп планлаштыру мондый бинаның чикләрен һәм (яисә) мәйданын үзгәртүдән һәм (яисә) яңа биналар булдырудан, шул исәптән әлеге Кодексның 40 статьясында каралган очракларда, һәм (яисә) аның эчке планлаштыруын үзгәртүдән (шул исәптән бинаның чикләрен һәм (яисә) мәйданын үзгәртмичә) гыйбарәт. Бинаны яңадан планлаштыру нәтиҗәсендә чиктәш биналарның чикләре һәм (яисә) мәйданы да үзгәртелергә мөмкин. Яңадан планлаштыру бинаның (урыннарның) чикләре һәм (яисә) мәйданы турында Бердәм дәүләт күчемсез мөлкәт реестры белешмәләренә үзгәрешләр кертү яисә төзелгән биналарны дәүләт кадастр исәбенә алу һәм төзелгән биналарга хокукны дәүләт теркәвенә алу зарурлыгына китерә».

2. Әлеге карар Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында рәсми басылып чыккан көннән законлы көченә керә (http://pravo.tatarstan.ru), шулай ук Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында (http://buinsk.tatarstan.ru) урнаштырылырга тиеш.

3.Әлеге карарның үтәлешен тикшереп тотуны үземдә калдырам.

Татарстан Республикасы Буа муниципаль
районының Күл Черкене авыл җирлеге
башкарма комитеты җитәкчесе М.К.Истиев